ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**29.03.2023ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 902**

2023 елга салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2007 елның 13 июлендәге «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 266 660 сум;
1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен - 2 533 320 сум;
1.1.3.өч кешедән торган гаилә өчен - 3 799 980сум;
1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен - 5 066 640 сум;
1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен - 6 333 300 сум;
1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен - 7 599 960 сум;
1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен - 8 866 620 сум.

1.2. һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1 ялгыз яшәүче граждан өчен - 23 918,18 сум. ;
1.2.2. Иие кешедән торган гаилә өчен - 23 918,18 сум;
1.2.3. Өч кешедән һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен - 23 918,18 сум.

2. «Зеленодольск муниципаль районы торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрен торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә кую вакытында кулланырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2023 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск

муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин

2023 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү
МЕТОДИКАСЫ

1. Муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алу өчен базар хакының исәп-хисап күрсәткече

СЖ= НП*РС *РЦ, биредә

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;
НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;
РС - гаилә әгъзалары саны;
РЦ - торак урын мәйданының бер квадрат метрының Зеленодольск һәм Зеленодольск муниципаль районында торак урыннар бәясенең уртача күрсәткеченә туры килә торган уртача исәп-хисап базар хакы (2023 ел башына - 70 370 сум).

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
СЖ= 70 370*18*1 = 1 266 660
б) ике кешедән торган гаиләгә:
СЖ=70 370*18*2= 2 533 320
в) өч кешедән торган гаиләгә:
СЖ=70 370*18*3= 3 799 980
г) дүрт кешедән торган гаиләгә:
СЖ=70 370*18*4= 5 066 640
д) биш кешедән торган гаиләгә:
СЖ=70 370*18*5= 6 333 300
ж) алты кешелек гаиләгә:
СЖ=70 370*18*6= 7 599 960
з) җиде кешедәнторган гаиләгә:
СЖ=70 370*18*7= 8 866 620

2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме

ПД=0,7*СЖ*ПС / (1-(1+ПС)-КП) / (0,3*РС), биредә

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;
ПС - кредит буенча процент ставкасы (7,5% / 12);
КП - кредитның бөтен срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);
РС - гаилә әгъзалары саны;
0,7 - кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;
0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте;

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
ПД=0,7*1 266 660*0,0063 / (1-(1+0,0063)-240) / (0,3*1) = 23 918,18
б) ике кешедән торган гаиләгә:
ПД=0,7*2 533 320*0,0063 / (1-(1+0,0063)-240) / (0,3*2) = 23 918,18
в) өч кешедән һәм аннан да күбрәк кеше торган гаиләгә:
ПД=0,7*3 799 980*0,0063 / (1-(1+0,0063)-240) / (0,3*3) = 23 918,18
г) дүрт кешедән һәм аннан да күбрәк кеше торган гаиләгә:
ПД=0,7*5 066 640*0,0063 / (1-(1+0,0063)-240) / (0,3*4) = 23 918,18